СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

24.01.2020 Әгерҗе шәһәре № 44-5

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2018 елның 17 октябрендәге 30-4 номерлы карары белән расланган тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы муниципаль хезмәткәренә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Хезмәт кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 16 декабрендәге 439-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, 2019 елның 16 декабрендәге 436-ФЗ номерлы ««Мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 2018 елның 17 октябрендәге 30-4 номерлы карары белән расланган тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы муниципаль хезмәткәренә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү тәртибе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5нче пунктта «хезмәт кенәгәсенең күчермәләре» сүзләреннән соң «һәм (яки) хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр» дигән сүзләр белән тулыландырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (http://agryz.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының бюджет, салымнар һәм финанслар буенча даими комитетына йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы,
Совет Рәисе В.В. МАКАРОВ